**УКАЗ**
ПРЕЗИДЕНТА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ПРЕЗИДЕНТЫ
**УКАЗЫ**

**Үсемлекләр дөньясыннан файдалану һәм аны саклау, төбәк әһәмиятенә ия булган аеруча саклanучы табигать территорияләрен оештыру, аларның эшчәнлеге, аларны саклау һәм файдалану, Татарстан Республикасының Кызыл китабын алып бару өлкәсендә дәүләт идарәсе мәсьәләләре**

Татарстан Республикасы Конституциясенең 94 статьясы һәм «Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары турында» 2005 елның 6 апрелендәге 64-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә **карар бирәм:**

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының моңа кадәр Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгы тарафыннан гамәлгә ашырылган түбәндәге функцияләрен һәм вәкаләтләрен:

үсемлекләр дөньясыннан файдалану өлкәсендә мөнәсәбәтләрне җайга салуны;

төбәк әһәмиятенә ия булган аеруча саклanучы табигать территорияләрен оештыру, аларның эшчәнлеге өлкәсендә идарә итүне, Татарстан Республикасы Кызыл китабын алып баруны;

үсемлекләр дөньясы объектларын саклау өлкәсендә төбәк дәүләт экология күзәтчелеген;

төбәк әһәмиятенә ия булган аеруча саклanучы табигать территорияләрен саклау һәм алардан файдалану өлкәсендә төбәк дәүләт күзәтчелеген Татарстан Республикасының Хайваннар дөньясы объектларын саклау һәм алардан файдалану идарәсенә тапшыру турындагы тәкъдиме белән килешергә.

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына:

Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгының әлеге Указның 1 пунктында санап кителгән функцияләрен һәм вәкаләтләрен законнарда билгеләнгән тәртиптә Татарстан Республикасының Хайваннар дөньясы объектларын саклау һәм алардан файдалану идарәсенә тапшыруны тәэмин итәргә;

өч ай эчендә Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгы структурасын һәм Татарстан Республикасының Хайваннар дөньясы объектларын саклау һәм алардан файдалану идарәсенең законнарда

билгеләнгән тәртиптә вәкаләтле федераль башкарма хакимият органы белән килештерелгән структурасын раслауга тапшырырга;

үз актларын әлеге Указга туры китерергә, шулай ук аны гамәлгә ашыруга бәйле башка карарлар кабул итәргә.

3. Әлеге Указ аңа кул куйган көннән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Президенты** **Р.Н. Миңнеханов**

Казан,Кремль
2017 ел, 03 февраль
№ ПУ-95